| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**Табарлинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Тәбәрле авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2022 Тәбәрле № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Аккуҗа торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е :

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Аккуҗа тор ак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 23 ноябрендә 13 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Аккуҗа торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы

затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Яңа Аккуҗа авылындагы урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү һәм хезмәт килешүе буенча штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт хакы түләү;

- Яңа Аккуҗа авылында юлларга хезмәт күрсәтү (карны чистарту), үләннәр чабу, (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт хакы түләү);

- Яңа Аккуҗа авылында су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосы сатып алу;

- Яңа Аккуҗа авылы территориясен төзекләндерү буенча чаралар

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Яңа Аккуҗа авылы, Ленин урамы, 34б йорт, авыл клубында үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Салимуллин

Совет Табарлинского сельского поселения
Тәбәрле авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002519
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ